

Эх, гомер юллары... Ургылып аккан ташу сулары кебек, әле бер ярга, әле икенче ярга бәрелә-бәрелә каядыр агасын да агасын. Каласы иде шул яшьлек ярларында. Юк, адәм баласына бирелмәгән андый момкинлек. Кеше гомере - агымсу – уза да китә икән. Кабатланмас тормыш юлында ачысын һәм точесен аз татымаган сугыш чоры баласы, Ромоданово районы Алтар авылында гомер итүче Залфа Сабир кызы Мяксеняеванын беләсе иде, нинди тостәге жепләрдән чигелгән икән ул 90 еллык гомер тукымасы?! Тугызан еллык гомер эчендә күпне күргә туры килгән язма героебызга. Залфа Сабир кызы тумышы Башкортстаннан. Тормыш агымсуга тинләсәләр дә, балачак якты мизгел буларак һәрвакыт хәтердә. Ул, истәлекләрен янартып: «Безнен гаиләдә, яше-карты, музыканы бик ярата идек. Әтием гармунын бик тә матур уйнатты. Кичләрен, үзенен гармунын кулга алуга, гаилә кешеләре барысы да борынгы жырларны суза башлый идек; кич утырырга тирә-күрше дә жыела торган иде».

Залфа Сабир кызы авыл мәктәбенен жиденче сыйныфын тәмамлагач, дәһшәтле Боек Ватан сугышы башлана. Ачлы-туклы яшүсмер еллары... Үндүрт яшьлек кыз бала сугыш елларындагы авыр хезмәтне үз жилкәсендә татыгын. 1941 елны ук, яшьтәшләре белән бергә, Оренбург олкәсенә торф әзерләргә жибәрелә. Шулай ук жәй коннәре якташлары, яшьтәшләре һәм картлар белән бергә, ашлыкны чәчеп урганнар, киндер эшкәрткәннәр. Кышларын фронтка дип йон эрләп бияләйләр, оекбашлар бәйләгәннәр. Халык тошенкелеккә бирелмәгән; дошманны жинүгә ышанганнар. Урман кискәннәр алар. Хезмәт фронтында эш житәрлек булган: күп авырлыклар кичергән Залфа апа. Жинүгә керткән олы олеше очен анын алдында һәм бу дәвер кешеләр алдында, баш иябез бүген. Боек Ватан сугышы тәмамлангач, Илне торгызу еллары башлана. Залфа Сабир кызы Мяксеняевага Оренбург олкәсе тозелешләренә эшкә китәргә туры килә. Һәм нәкъ шунда Ромодан районы Алтар авылында туган, Боек Ватан сугышында катнашып инвалид калган Исхак Сәләхетдин улы Мяксиняев белән очраша. Мәхәббәтләре гаилә буларак яши башлый. Тормыш иптәшенен туган авылында, Алтарда, ой тозиләр. Аларнын уллары һәм оч кызлары туа. Тату гаилә матур яши. Кызганычка каршы, бүген Исхак Сәләхетдин

улынын ныкжилкәсе янында юкинде Залфа апанын. Әмма балалары һәм яраткан оныклары бер минутка да соекле Әниләрен һәм әбиләрен игътибарсыз калдырмыйлар. Юбилярыбыз зур һәм матур йортта олы кызы Альмира белән бергә яши.
Залфа Сабир кызы Мяксеняева хезмәт биографиясенен kvп олешен сату эшенә багышлый. Анын тырыш хезмәте мактау кәгазьләре белән билгеләнә. Ул хезмәт ветераны исемен лаеклы йортә.
Урнашылган гадәт буенча, сентябрь башында, район һәм авыл администрациясе, ветераннар оешмасы вәкилләре, зур делегация буларак, Алтар авылында гомер иткән, 90 яшен тутырган Залфа Сабир кызы Мяксеняева йортына киләләр. Бу гаилә, юбиляр белән бергә, кунакларны якты йоз белән каршы ала. Залфа Сабир кызы башта илебез Президенты В.В. Путиннан котлау телеграммасын кабул итә, аннары Ромоданово муниципаль район житәкчесе А.А. Гурьяновтан бvләкне ала, эчтәлекле котлау сvзләрен район Советы белән ветераннар комитеты, авыл администрациясе ишеттерә.
Хезмәт ветераны Залфа Сабир кызы, тормышнын ачысын-точесен kvргән булса да, якыннарынын якты монәсәбәтләре, кадер-хормәтләре очен, хокvмәтнен олкән буынга kvрсәткән ярдәме һәм анлаулары очен, рәхмәтле.

Наилә Насырова